ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 март 2018ел № 1053

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 нче карары белән расланган Җир участокларының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы тарафыннан «Төзелеш һәм территориаль планлаштыру өчен рөхсәт алу» максатчан моделенең «җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү буенча хезмәт күрсәтү срогы» 2.1.1.1 күрсәткеченә ирешү мәсьәләсе буенча 2017 елның 15 ноябрендәге киңәшмә беркетмәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 нче карары (Башкарма комитетның 2015 елның 4 сентябрендәге 4936 нчы, 2016 елның 27 июнендәге 3281 нче, 2017 елның 31 августындагы 5059 нчы карарлары редакциясендә) белән расланган Җир участокларының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәтне күрсәтү срогы | гариза теркәлгән вакыттан башлап 17 эш көнендә | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсенең 6 бүлеге |

2) 3.4.2 пунктның 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт нигезендә билгеләнә торган процедуралар, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнарга туры китереп кабул ителгән Татарстан Республикасының

норматив хокукый актлары нигезендә ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, мәгълүматлар белән тәэмин итүчегә ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 3.5.1 пунктның 5 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт нигезендә билгеләнә торган процедуралар мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең ведомствоара запроска җаваплары архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында рәсми бастыруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                Р.Ә. Абдуллин